5 тиен

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ
1 9 6 3

4

Ш. МӨДӘРРИС



# ЙОЛДЫЗ АТЫЛА



ШӘРӘФ МӨДӘРРИС



# ЙОЛДЫЗ АТЫЛА

ПОЭМА-ОЧЕРК

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1963

С(ТАТ.)2
М97

*УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН*



## 1. ПИОНЕР ИСЕМЕ

Элек булган мәдрәсә,
Мәктәп хәзер монда.
Ауган, иңгән, черегән,
Батып тора моңга.

Иртән-кичен намазга
Диндарларны дәшеп, —
Безнең өскә дию күк
Басып торды мәчет.

Авыз, ахры, ерылган,
Йөзем, ахры, көләч.
...Тотып алды тыкрыкта
Галәветдин пеләш.

— Аклар килгән Сембергә,
Йөзме-меңме вагун!
Мәче кебек асарлар
Сине, денсез камун!

...Качып китәм йөгереп,
Үкчәм тими җиргә.
Галстугым җилферди,
Канат җәеп җилгә.

...Бирә тотып күз төпкә
Күрше егет — Фарук.
— Монысы әлегә чаткысы,
Урының булыр тәмуг!

Таяк тотып, каршыга
Чыга Хисам бабай.
— Муенчагың бозауга
Бәйлә, ахмак малай!

Өйгә керәм. Бу ни хәл?
Түрдә — Кәбир мулла.
Төкеренеп, шомланып,
Карый уңга-сулга.



— Ашың ятмый йөрәккә,
Ярый, сау бул, Бикә!
...Мулла, укып бәддога,
Өйдән чыгып китә.

Котлый мине стенадан
Китек читле көзге.
Муенымдагы галстук
Алсу иткән йөзне...



Зак. 1020. — 2.

Төрле-төрле типтагы
«Корал» белән тула.
Җиңеп чыкты «тынычлык»,
Тынып калды авыл.
...Еллар үтте, чикләрдә
Купты ләкин давыл.
Солдат булып, чын корал
Алдык шул чак кулга.
...Соңгы гильза чәчрәде
Безнең кайтыр юлга.
Яңрый бүген тынычлык,
Иҗат, хезмәт җыры.
Кайчан килер дөньяга
Коралсызлану чоры!?

## 5. БЕЗНЕҢ «КЫЗЫЛ ГАЕТ»

Гает җиткән, имештер,

Карт-корыны кара:
Атлый-туктый, мәчеткә
Тәкбир әйтеп бара.

Без дә киттек мәктәпкә,
Начар түгел кәеф:
Анда бүген иртәлек —
Безнең «кызыл гает».

Җыела барлык балалар,
Активистлар килә.
Хатын-кызлар, агайлар,
Кереп, сәлам бирә.





Безгә карап күз кысты
Мөдир абый — Гата.
Гармун уйный «таз» Хәлим,
Җырлый «денсез» Вафа.

...«Чалма» киеп, «мөмбәр»гә
«Артист» Сәет чыга;
Кәмит итеп, көлдереп,
«Укый» сәер «дога».



Яңрый сафта «Наганым»,
«Варшавянка» яңрый.

Җилдек кире әйләнеп,
Кибет алды — халык.
Шакир абый баскычта
Тора уйга талып.

Сирпи саф җил чал чәчен,
Җиндә — кызыл тасма.
Кычкыралар түбәннән:
— Әйдә, Шакир, башла!

Сөйли Шакир: — Ибдәшләр,
Совет мәңге үлмәс!
Котлы булсын хөррият,
Октябрьга ун яшь!



Торган саен көчлерәк,
Гайрәтлерәк янсын
Ленин бабай кабызган
Революцион ялкын!

...Куштан Вәли кычкыра:
«Бабай» дисең! Ташла!
Ленин синнән, туганкай,
Унбиш яшькә яшь лә!

— Яп син салма савытың!
Сукалама өстән!
Ленин миннән йөз яшькә,
Мең яшькә дә өлкән!

Ярый, ул яшь, килешәм,
Һәм ул гел яшь калыр!
Яшьтәш булып, киләчәк
Буыннарга барыр!

...Куштан Вәли ычкынды,
«Бәла килмәс борын»...
Шакир абый башлады
«Бәйнәлмиләл» җырын.

### 9. «ДУСЛЫК КӨНЕ».

Барсы әзер мәктәптә,
Бүген — «Дуслык көне».
Лозунгларда — рус, татар,
Чуваш, мукшы теле.
Чакырылды кунакка
Безнең бөтен тирә:
Җилә Шамкин, Баешлар,


Алмалылар килә.
Нәҗип абый отрядны
Тезде өч зур сафка.
Чыгып киттек авылдан
Төрле-төрле якка.
Каршылыйбыз дусларны
Тантаналы итеп;
Каршылыйбыз авылдан
Ераккарак китеп.
Чуваш дуслар Баештан
Чиккә килеп төшә.
Аргы очта «вәкил»ләр
Шамкиннарны көтә.
Күреп алдык ерактан
Алмалылар сафын.
Җыр, быргы һәм барабан...
Дуслар инде якын!
Яңгыратты «ур-ра»лар
Аргы-бирге очны.
Күккә кызыл тасмалы
Московкалар очты.
Көнне, кичне үткәрдек,
Уйнап, җырлап биеп.
«Бәйнәлмиләл» моңнарын
Кабатладык сөеп.
Таралыштык өйләргә
Җәйге ал таң тугач.
Минем кунак малайлар —
Рус, мукшы һәм чуваш.
Ашап-эчкәч, йокладык
Печәнлеккә ятып.
Иртән безне канәфер
Котлый, чәчәк атып...





## 10. КОСТЕР ЯНЫНДА

Лагерь яхшы, тамак тук,
Шундый әйбәт урман!
Ләкин бер дә алмыйбыз
Күзне кайтыр юлдан.
Әллә качып китикме? —
Сагындыра авыл.
Әти, әни булмагач,
Әллә ничек, авыр...



Ахры, «Кара такта»га
Яздырырсың мине...
Әни, өйрән «Әлифба»ң,
Торып торсын бар эш.
Бер айдан соң зурларга
Була бездә ярыш!
Бер айдан соң... Һай, бу сүз!
Тырный һаман эчне.
Минем «шәкерт», сынатып,
Бозмас микән эшне?
Безгә бурыч куйдылар:
— Чәчик белем һәм аң!
Наданлыгын бетерсен
Башта атаң-анаң!
Пионерлар һәммәсе



«Хәлфә» булды өйдә.
— Әткәй, әнкәй, килегез,
Дәрес карыйк, әйдә!
Үтте бер ай. Мәктәпкә
Тулды кичен халык.
Килде зурлар, карандаш,
Дәфтәр, китап алып,
Менә ярыш башланды.
Хәмит тора янда:
— Минем әти — молодец,
Барысыннан алда!
...Шатландыра өлкәннәр
Бик шәп язып, укып.
Минем әни шыр надан,
Инде күпме тукып...
Хурлык! «Кара такта»га
Чыгардылар мине...
Әнием әйтте: — Кайгырма,
Өйрәнермен, — диде...

## 15. АЙ, БУ БОЙКОТ!

Отрядыбыз бик әйбәт,
«Мораль яктан» таза.
Тәртипсезгә һич көн юк:
Бойкот [1] — иң зур җәза.
Эләктеңме бойкотка,
Инде, туган, чыда!
Арбаң тигез барганда
Тәгәрмәчең чыга...

[1] Биредә берәр кешегә сүз дәшмәү, аның белән кул биреп күрешмәү мәгънәсендә алына.

Күрше отряд күп еллар
«Трофей» итеп тотты.
...Инде бездә бүтәннәр
Торды байрак карап.
Үксеп-үксеп яшь койды
Азат белән Гарәф...
— Пионер, сакла байракны,
Күз караң күк сакла!
...Сугыш булды. Без шунда
Бастык тагын сафка.
...Бөтен штаб камалды,
Барсы калды авып.
Шулчак полк байрагын
Гарәф чыкты алып.
...Ерак юлга рейдлар,
Разведкалар ясап, —
Дошман полкы байрагын
Алып кайтты Азат.

## 18. ТРАКТОР КИЛДЕ

Кырда сарык карыйбыз,
Язның матур төне.
Учактагы кылганны
Ялый ялкын теле.

Кайнар көлдә бәрәңге,
Инде ул да пешә.
Чү, нәрсә бу? Калкудан
Утлар шуып төшә.

Әллә нинди гөрелдәү,
Таныш түгел, сәер.






Шомландыра нигәдер,
Ай да бар ич, хәер...

«Шулай итеп, Таз малай
Сәмруг кошта бара...»
Әкиятчебез Нургали
Кинәт туктап кала.

Ярхәм куйды кычкырып:
— Менә бу эш ярый!
Алып кайта трактор,
Безнең Мирхан абый!



Һәр көн безгә бирәләр
Җирәк кадәр дары.

Катумкага тотырып,
Ярты көнлек азык;
Кара атлар йөгәнләп,
Соры этләр алып, —

Пионерлар кичкырын
Кырга чыгып китә.
Ярты төннән соң, тагын
Алмаш килеп җитә.



Засадалар корабыз,
Зурат төбенә ятып;
Хәбәрләшеп торабыз,
Каланчадан атып.


Шакир абый булмәсе
Көнен-төнен ачык.
Рапорт бир дә кич-иртән,
Тагын кырга ашык.

Ике-өч патрон запаста,
Кургаш ядрә — авыр.
Килсә явыз караклар,
Җирәкләрен алыр!

Рәхмәт, туган колхозым,
Ышанганың өчен! —
Иң тәүге кат иснәдек
Шунда дары исен...

## 20. КУБА ҖИҢӘР!

Матур, бөек, данлыклы
Куба узган юллар!
Төшә бүген хәтергә
Утызынчы еллар...
Карталардан күзәттек
Без гел океан артын.
Кайнап торды Утрауда
Революцион ялкын.
Канлы тиран Мачадо
Торды кылыч айкап.
Диңгез-океан өстеннән



Янки керде атлап.
Менә хәбәр: бар халык
Палачларны куган.
Мабей, Хирон, Сенадо
Советлары [1] туган.

[1] 1933 нче елда Кубада бөтен халык восстаниесе АКШ ялчылары Мачадо һәм Сеспедес диктатурасын бәреп төшерде. Гомумән, андагы каты революцион сугышлар 1930—1935 еллар буена дәвам итте.



Мәктәп гөрли: — Тантана!
— Куба азат бүген!
...Пионерлар алкышлый
Газый абый сүзен.
— Социалистик хөр ватан
Булыр хәзер ул да!
— Азат негр, мулатлар!
— Куба азат! Ур-ра!
Шул көн мин дә хисемне
Җырларыма салам:
Имеш, азат Утрауга
Планер белән барам...
...Сүнеп калды бер заман
Утраудагы якты.
Шомлы янки шәүләсе
Куба өстен япты.
Торды тиран Батиста
Утрау канын имеп.
Җинде ләкин Азатлык,
Килде ләкин Ирек!
Куба азат, без дә шат,
Коллык чоры китә!
...Пионер кызым Фидельгә
Бер хат язды кичә:
— «Шалтыратып богавын,
Чиксен янки азап.
Куба инде җиңелмәс,
Куба мәңге азат!
Азат Утрау алдында
Көчсез ут та, су да.
Сезнең белән без бергә,
Куба җиңәр, Куба!»

Чиктә янгын кабынгач,
Шомлы шәүлә сузып,—
Сугышларга ыргылдык,
Комсомолец булып.

Онытмадык ләкин без
Галстуклы сафны;
— «Әзер бул!» — «Без һәрвакыт
Әзер!» — дигән чакны.

Һәлак булды күбебез,
Калды җырга кереп, —
Отряд сөеп җырлаган
«Барабанчы» кебек.

Намус белән үттек без
Авыр сугыш чорын;
Алып бардык Эльбага
Мәңге яшәү җырын.

Рейхстагка мендерде
Җанда янган саф ут.
Бирдек аннан Ватанга
Пионерларча салют.

Күбебезнең күкрәге
Орден белән тулып, —
Алдык Ленин мандаты,
Партияле булып.



Безнең буын күп күрде,
«Кырау»да бар чәчтә.
Заман белән атлыйбыз, —
Без кырык биш яшьтә!

Лачын итеп очыртыр,
Һаман алга карап, —
Пионер чакта чыгарган
Безнең ныклы канат.

*Октябрь — декабрь, 1962*



*Шараф Мударрис*
(Мударрисов Шараф Хасиятуллович)

ПАДАЮЩИЕ ЗВЕЗДЫ

(на татарском языке)

Редакторы *Х. Камалов*

Художнигы *С. Кульбака*

Техник редакторы *Ф. Габдуллаҗанова*

Корректоры *С. Насыйбуллина*

Наборга бирелде 31/VII-63 ел. Басарга кул куелды 7/X-63 ел.
ПФ 17231. Кәгазь форматы $70 \times 90^1/_{32}$. Учет.-изд. табак 1,61.
Басма табак 1,38(1,61). Заказ Ш-1020. Тираж 7000 экз.
Бәясе 5 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды.
Казан, Бауман урамы, 19, 1963 ел.